КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 28 май г.Казань № 382

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасында санитар-эпидемиологик хәлне һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы таралу үзенчәлекләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 15 август, 687 нче, 2020 ел, 2 сентябрь, 774 нче, 2020 ел, 18 сентябрь, 847 нче; 2020 ел, 29 октябрь, 970 нче; 2020 ел, 5 ноябрь, 995 нче; 2020 ел, 14 ноябрь, 2020 ел, 30 ноябрь, 1077 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктта:

өченче абзацта «мондый биналар һәм корылмалар урнашкан җир кишәрлекләрендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

дүртенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

алтынчы абзацта икенче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Куллланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән (алга таба – Россия кулланучылар күзәтчелеге идарәсе) Россия кулланучылар күзәтчелеге идарәсенә оешманың штат расписаниесе һәм барлык хезмәткәрләргә карата «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан) Covid-19дан профилактика характерындагы прививкалар сертификатлары күчермәләре, шулай ук медицина

ягыннан зарарлы булуын күрсәтә торган билгеләре булу турындагы документлар күчермәләре теркәп җибәрелгән хәбәрнамә нигезендә бирелгән килешүнамә булганда, әлеге чикләү барлык хезмәткәрләренә (медицина оешмасының белешмә кәгазе (медицина бәяләмәсе) белән расланган вакцинация ясауга карата медицина ягыннан зарарлы булуын күрсәтә торган билгеләре булган затлардан тыш) штат расписаниесе нигезендә яңа коронавирус йогышлы авыруына каршы вакцинация ясалган җәмәгать туклануы оешмалары тарафыннан җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәтүгә кагылмый.»;

6 пунктта:

«в» һәм «з» пунктчалары үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карарга теркәлгән 1 нче кушымтада:

1 пунктта:

1 пунктчада «һәм, кирәк булганда,», «территорияләрдә», «кулларны шәхси саклау чараларын (перчаткалар)» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 пунктчада «, шулай ук эш көне дәвамында эш урыннарында һәм (яки) эш бирүче территориясендә хезмәткәрләрнең тән температурасын алга таба дүрт сәгатькә кимендә бер тапкыр тәкъдим ителә торган вакыт аралыгы белән үлчәргә» сүзләрен төшереп калдырырга;

5 пунктчада «бүлмәләрдә,» сүзләреннән соң – «билгеләнгән тәртиптә теркәлгән,» сүзләрен «вирусларны һәм микроорганизмнарны бетерә торган йогышсызландыру чараларын» сүзләреннән соң «алга таба – вирусларны һәм микроорганизмнарны бетерә торган йогышсызландыру чаралары)» сүзләрен өстәргә;

8 пунктчада «кулларны тире антисептиклары» сүзләрен «кулларны билгеләнгән тәртиптә теркәлгән, вирусларны һәм микроорганизмнарны бетерә торган тире антисептиклары (алга таба – тире антисептиклары)» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктта:

1 пунктчада «мондый биналар һәм корылмалар урнашкан җир кишәрлекләрендә,» сүзләрен төшереп калдырырга;

4 пунктчада «һәм кулларны шәхси саклау чараларын (перчаткалар)» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Оешмаларга һәм индивидуаль эшмәкәрләргә түбәндәгеләр тәкъдим ителә:

65 яшьтән өлкәнрәк хезмәткәрләрнең һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына теркәлгән 2 нче кушымтада күрсәтелгән авырулары булган гражданнарның эшен нигездә дистанцион формада оештыру;

хезмәткәрләрнең чит затлар белән аралашуын чикләү максаты белән аларны эш урынына кадәр алып баруны һәм аннан алып кайтуны оештыру.».

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин